ДУХОВНО-ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ГАЗЕТА РЕГИОНАЛЬНОГО
ДУХОВНОГО УПРАВЛЕНИЯ МУСУЛЬМАН
САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ
И САМАРСКОЙ СОБОРНОЙ МЕЧЕТИ

*Самар өлкәсе җирле мөселман дини идарәсе һәм
Самар Җәмигъ мәчетенең
рухи-мәгърифәтчелек басмасы*

# Ислам-Нур

№ 24 (83), 27 декабря 2012 г.
14 Сафар 1434 г.

**Юбилейлар**

# *Иске мәчетебезгә - 45 ел!*



Ислам дине авыр сынаулар кичерсә дә, ул халыкның күңелендә, йөрәк түрендә сакланып килде. Мәчетләребезне җимереп, имамнарыбызны зинданнарга япканда да динебез Ислам югалмады.

Бөтен илдәге кебек, Самар татарлары да дини йолаларны, гореф-гадәтләребезне үтәп, Ислам динен һәм милләтебезне саклап килделәр. Мәчет булдыру халык күңелендәге матур бер хыял булып, торган саен көчәя барды.

**Ниһаять, 1967 елның 7 декабрендә Малый Тупик урамында хәзерге Иске мәчет төзелеп сафка басты. Аны булдыру юлындагы авырлыклар, халык тарафыннан күрсәтелгән тугрылык - үзе бер тарих.**

Бу мәчет төзелүгә менә 45 ел үтеп тә китте. Аны торгызуда күп көч куйган милләттәшләребезнең, дин кардәшләребезнең күбесе инде фани дөньяга күчтеләр.

12 декабрь көнне Самар Җәмигъ мәчетендә Малый тупик урамындагы Иске мәчет төзелүгә 45 ел тулу уңаеннан мәҗлес узды. Табында Коръән укылып, истәлекләр яңартылды. Мәчет төзүдә башлап йөргән һәм әлегә кадәр эшләп килгән дин әһелләренең, имамнарның, мәхәллә рәисләренең исемнәре телгә алынды, мәрхүм булганнарның рухына багышлап догалар кылынды.

Талип хәзрәт Яруллин, Үзәк Диния нәзарәте казые Вагыйз хәзрәт Яруллин вәгазьләр сөйләделәр.

**Иске мәчет тарихы турында сөйләр өчен «Азан» газетасы мөхәррире Шамил Галимовка сүз бирелде, һәм ул түбәндәгеләрне сөйләде.**

- Малый Тупиктагы мәчетебез - ул Самар тарихында саны буенча бишенче мәчет. Моңа кадәр булганнары турында сез, китап-газеталарны укып торучылар, яхшы беләсез - алар урнашкан җирләр хәзерге Самарская, Фрунзе, Алексей Толстой һәм Оренбургская урамнары.

Үткән гасырларның бер өлешендә генә Самар татарлары мәчетсез яшәгән. Шул чор илебездә динсезлек хакимлек иткән елларга туры килә. Совет власте килгәч, 1930 елда хәзерге Спорт сарае урынында булган Җәмигъ мәчете ябыла һәм аның манарасы киселә.

Ә 1932 елның февраль аенда Казанская - Оборона урамындагы мәчетебез дә мөселманнардан тартып алынды.

Шуннан соң динебезгә кара көннәр килә. Совет власте халыкны диннән аерыр өчен нәрсә генә эшләми. Мәчетләрнең барысы да диярлек ябыла, шул елларда күп муллалар атып үтерелә, төрмәгә утыртыла һәм сөргенгә озатыла.

Ләкин Совет властенең тырышулары уңышсыз булып чыга - ул мөселманнарның дингә, ата-бабалардан килгән гореф-гадәтләрне саклап калырга омтылуларын тәмам юкка чыгара алмый. 35 ел буена Самара - Куйбышевта яшәүче татарлар мәчет булдыру нияте белән яшәгәннәр. Бөек Ватан сугышы тәмамланып барганда, 1945 елның язында, иң батыр агайларабыз төрле дәүләт органнарына ике мәчетнең берсен булса да кайтару үтенече белән йөри башлаганнар. Аларны Йосыф Якупов исемле кеше җитәкләгән. Шул вакытта шәһәрдә мөселман тормышы бер дә туктамаган, мәҗлесләр уздырылып торган, халык качып, аерым өйләрдә һәм сарайларда җомгалар, зиратка җыелып, гает намазлары укыган. Өч мулла - Ибраһим Ганиев, Габбас Галиев, Исмәгыйл Хәмзин, мәзин Фәттах бабай халыкны берләштереп, барлык дини гадәтләребезне үтәп килгәннәр. Мәчет кебек биналар төзү очраклары да булган.

Егерме ел буена безнең иң абруйлы бабаларыбыз, бер-берсен алмаштырып, югары кабинетларга мәчетләрне кайтару йә булмаса яңа мәчет булдырырга рөхсәт сорап, бертуктаусыз йөреп торганннар. Шулар арасында Хәйрулла Гыйлманов, Мортаза Әюпов, Рамазан Кәбиров, Усман һәм Рәшит Вәлшиннар, Габделәхәт Әмиров һәм башкалар бар.

Ниһаять, 1967 елның 7 декабрендә Куйбышев шәһәр советы мөселманнарга Малый Тупик урамында 127нче йортны сатып алып, анда гыйбадәтханә корырга рөхсәт биргән. Ул инде Иске мәчетебезнең барлыкка килүе көне булып санала.

Аның беренче имамы итеп Ибраһим мулла Ганиев сайлана. Ул вафат булгач, 1968 елның 10 сентябрендә имамлыкка Кәшшафетдин Шәрәфетдинов керә, аннан соң 1976 елда бу урынга Сәетәкрәм бабай Мустаев сайлана, ә инде 1983 елның беренче октябрендә халык бертавыштан имам вазифасын Вагыйз хәзрәт Яруллинга йөкли. Шул вакыттан бирле инде 30 елга якын хөрмәтле хәзрәтебез Самар һәм өлкә мөселманнары җәмгыятенә хезмәт итә. Ул өлкә Диния нәзарәте рәисе итеп сайлангач, Иске мәчетнең имамы булып Талип хәзрәт калды. Бүгенге көндә мәхәлләне яңадан Вагыйз хәзрәт Яруллин җитәкли.

Шул 45 ел дәвамында мәчетнең хуҗалык эшләрен алып баручы мөтәвәллият рәисләрен дә атап үтик - ул Хәйрулла Гыйлманов, Газизулла Җиһаншин, Шәһит Абдуллов, Габделбари Мөхәммәтгалиев, Вагыйз Кадыйров, Исмәгыйл Фәткуллов, Галимҗан Авзалов, Талип Яруллин. Бер арада Вагыйз хәзрәт үзе мөтәвәллият рәисе булып та эшләде.

Шул елларда исәп-хисап эшләрен җайга салырга һәм аларны тиешле дәрәҗәдә алып барырга да белемле, ихласлы кешеләр табылды - Шакир Мәһдиев, Сәетгали бабай, Муллагали бабай, Летфулла бабай, Мөнир Вәлшин, Рөстәм Фәйзуллов. Бүгенге көндә бу



хезмәтне Әминә Мортазина алып бара. Егерме елдан артык Иске мәчетебез бары тик халык акчасына, садакага гына тотылды. Ул шәһәр татарларының бердәнбер дини һәм җәмгыять үзәге булып торды. Күренекле шәхесләребез, Куйбыш байлары аңа һәрвакыт ярдәм итеп тордылар. Шулар арасында Моталлап Әюпов, Абдулкадыйр Әмиров, Сания Каюмованы әйтеп үтәргә кирәк.

Баштан Малый Тупикта уртача зурлыкта, тыйнак кына гыйбадәтханә йорты иде. Ә 1985 елда халыктан җыелган акчага ул зурайтылды, кечкенә генә булса да манарага ия булды, шулай итеп, тышкы күренеше белән дә мәчет сыйфатын алды. Бу төзү-сипләү эшен башкаручылар арасында Марат Сафин, Зәкәрия Нуруллин, Миргарифан Галәлетдинов, Мингата Сәяхов, Салихҗан Галләмов, Минәүхәт Мингачев һәм башка дин кардәшләребез булды.

**Ә инде 2005 елда Малый Тупиктагы мәчет 23 метр биеклектәге манара белән бизәлде һәм бүгенге матур кыяфәтенә керде.**

Иске мәчетебез безгә күз карасы кебек кадерле. Ул динебезнең иң авыр чакларында сакланып калуына бер сәбәп, ә 80нче еллар азагында дини һәм милли яңарышның бер чишмәсе булды.

* * *

**Әйе, хәзерге вакытта Самар шәһәрендә алты мәчет эшләп килә. Ял көннәрендә аларда дини укулар алып барыла. Бирегә килүчеләр саны елдан-ел арта бара. Мәчетләрдәге Ислам дәресләренә йөрүчеләр арасында хатын-кызларның күп булуы киләчәккә өмет бирә.**

Менә бу мәҗлестәге ак сакаллы, нурлы йөзле бабайлар - чын мәгънәдә дин сакчылары. Алар иң авыр елларда да үзләренең динлелеген, милли сыйфатларын, татарның затлылыгын саклап килгәннәр һәм бүгенге көндә барыбыз өчен дә тормыш үрнәкләре күрсәтеп яшиләр.

Өлкәбездә, шәһәребездә мәчетләр саны киләчәктә дә арта торыр, Аллаһы теләсә. Ләкин дә алар арасында беренче булып төзелгәннәре, элгәредән, дәһшәтле заманнардан сакланып килгәннәре аеруча хөрмәткә лаек.

Бу мәҗлес үткәннәрдән гыйбрәт алу, киләчәккә ышаныч һәм изге гамәлләр туплау, гореф-гадәтләрне саклау рәвеше булды. Иманнарыбызны ныгыта, рухыбызны баета һәм уңышыбызны үстерә торган чаралар киләчәктә дә шулай үткәрелеп торсалар, милләтебез, динебез сакланыр әле, Аллаһы теләсә.

***Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.***